**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 11 2021 № 382

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 31.06.2018, № 336 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 31.06.2018, № 336 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1-4 кушымталарның I бүлегендәге 2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«База оклады (вазыйфаи база оклады), хезмәт хакының база ставкасы - дәүләт яисә муниципаль учреждениенең эшче һәнәре яисә тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәр вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрнең, компенсация, стимуллаштыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, минималь оклады (вазыйфаи оклады), эш хакы ставкасы.»

1.2. 1-4 кушымталарның I бүлегендәге 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оклад (вазыйфаи оклад) - компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь аенда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәр хезмәтенә түләүнең билгеләп куелган күләме.».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев